# *“Беркем дә онытылмый, бернәрсә дә онытылмый!”*

**Бу бәйрәмне безнең балаларның онытырга хакы юк! Татар халкы башка халыклар кебек үк газиз Ватаныбызны илбасарлардан саклар өчен яуга китә. Һәр бала үзенең бу сугышта катнашкан карт бабасын белергә тиеш. Шуңа да безнең балалар читтә калмыйча Җиңү көне митингларында катнашалар, сугышта ятып калган авылдашларыбызның исемнәрен мәңгеләштергән обелискка чәчәкләр куялар. Быел сугыш чоры балалары белән очраштык, аларга шигырь, җыр – биюләр бүләк иттек.**










